| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 17.12.2021 | Казан ш. | № 699-53/тко-2021 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2019 № 11-55/тко карары кушымтасына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы территориясендә Көнбатыш эшчәнлек зонасы буенча «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторы хезмәтләрен күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2019 №11-55/тко карары белән билгеләнгән озак сроклы чик бердәм тарифларга 2022 елга үзгәреш кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2022 елга каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторы хезмәтләренә озак сроклы чик дәрәҗә бердәм тарифларга үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы территориясендә Көнбатыш эшчәнлек зонасында «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәтенә чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләү турында» 2019 елның 19 декабрендәге 11-55/тко номерлы карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2020 № 584-42/тко-2020, 23.12.2020 №587-45/тко-

2020, 30.06.2021 №107-12/тко-2021 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы С.В.Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2019 № 11-55/тко карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2021 № 699-53/тко-2021 карары редакциясендә) кушымта

«Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә Көнбатыш эшчәнлек зонасы буенча төбәк операторы хезмәтенә 2020-2022 елларга чик дәрәҗә бердәм тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы хезмәте күрсәтүгә чик бердәм тарифлар, сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | | 2021 ел | | 2022 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| 1 | "Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе" идарәче компаниясе" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 439,03 | 456,60 | 456,60 | 488,57 | 488,57 | 508,12 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 365,86 | 380,50 | 380,50 | 407,14 | 407,14 | 423,43 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге